

30 март конне Рузаевка районынын Татар-Пишлә урта мәктәбе тарафыннан кvп еллар язучы исемен йортә торган Шәриф Камал ижатына багышланган му-ниципаль тантаналы чаралар vткәрелде. Онлайн режимында узган чарада Ислам мәдәни vзәге директоры урынбасары Надия Низаметдин кызы Азисова да кат-нашты.

Ботен Рос-сия буенча бу коннәрдә Шәриф Камал декадасынын белем бирv һәм мәдәни чаралар циклы кысаларын-да дәресләр, мастер-клас-слар vткәрелә, язучы ижаты турында дискуссияләр һәм ижади конкурслар оештырыла, танылган галимнәрнен лекцияләре уза.

Үз чыгышында Н.Н.Азисова традицион конфессияләр руханилары инициатива-сы һәм Мордовия Республикасы Баш-лыгы Артем Алексеевич Здунов ярдәме белән рухи-әхлакый юнәлештәге 6 «пи-лот» мәктәп оештырылуын билгеләп vтте: 5 – православие, 1 – ислам юнә-леше буенча. Ислам юнәлешендә - Ру-заевка районы Татар-Пишлә урта го-муми белем бирv мәктәбендә. Мәктәп белән рухи-әхлакый vсеш олкәсендә татар, моселман традицияләрен саклау-га юнәлдерелгән уртак чаралар планы гамәлгә ашырыла.

- Сезнен белән бергә хезмәттәшлектә, без, vсеп килvче буынга, мирасыбыз-ны саклап кала һәм тапшыра алабыз. Безнен катлаулы вакытта нәрсә житми? Кешелеклелек. Яхшы рухи-әхлакый ба-гажлы шәхес тәрбияләv - безнен уртак бурычыбыз. Бу тренд булырга тиеш, - дип билгеләп vтте Надия Низаметдин кызы Азисова.